**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет составына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет төзү турында» 2013 елның 30 гыйнварындагы ПУ-71 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1098 номерлы, 2016 елның 7 маендагы ПУ-405 номерлы, 2017 елның 17 апрелендәге ПУ-310 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-308 номерлы һәм 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2020 елның 17 апрелендәге ПУ-236 номерлы, 2020 елның 5 ноябрендәге ПУ-727 номерлы һәм 2021 елның 16 февралендәге ПУ-147 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан И.Р. Гафуровны, А.М. Терентьевны, Д.И. Фәттаховны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Совет секретаре итеп раслап, Мөхәрләмов Руслан Роберт улын – Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесен;

Сафин Ленар Ринат улын – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча);

Сөләйманов Тимур Җәүдәт улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын;

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.С. Герасимовның – «Татарстан Республикасы удмурт милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча)»;

С.К. Жаксыбаевның – «Татарстан Республикасының «Казахстан» казах милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

В.Е. Козловның – «Педагогика, психология һәм социаль мәсьәләләр институты» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры (килешү буенча)»;

В.Н. Любченконың – «Татарстан Республикасының «Берләштерелгән украин милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча)»;

Р.М. Мөхәммәтшинның – «Россия ислам институты» югары белем бирү хосусый учреждениесе ректоры (килешү буенча)»;

Н.М. Сабитованың – «Татарстан Республикасының мордва милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

Д.А. Самаренкинның – «Татарстан Республикасында чуваш милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы советы рәисе (килешү буенча)»;

М.А. Скоблионокның – «Татарстан Республикасының яһүд милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча)»;

А.Ә. Тимерхановның – «Болгар ислам академиясе» югары белем бирү дини мәгариф оешмасы мөселман дини оешмасы ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча)»;

О.А. Третьяковның – «Татарстан Республикасының мари милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

Г.Ә. Хәсәновның – «Татарстан Республикасы башкорт милли-мәдәни мохтарияте – башкортлар корылтае (конгрессы)» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

М.М. Хухунашвилиның – «Казан шәһәре Вахитов районының «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры, Казан шәһәренең «Сиони» грузин милли-мәдәни мохтарияте» җирле иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча)»;

Д.Ф. Шакировның – «Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисенең беренче урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)»;

К.Г. Яковлевның – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы рәисе урынбасары (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 06 октябрь
№ ПУ-715